**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 май 2014 ел Казан шәһәре № 10-14/кс

***Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга тарифларны билгеләү турында***

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында" 7 декабрь, 2011 ел, № 416-ФЗ Федераль законга, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында" 13 май, 2013 ел, №406 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. Әлеге карарның кушымтасына таянып, эчәргә яраклы су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешмалар өчен, әлеге карарның кушымтасына килештереп, эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифларын билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 1 июленнән 2014 елның 31 декабренә кадәр үз көчендә була.

3. Бу кararга кушымтада күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны хәл итүче оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 гыйнвар, 2013 ел, № 6 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. «Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызу хезмәте өчен тарифлар турында» 15.11.2013 № 10-41/кс Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карары кушымтасының 2 пунктын үз көчен югалткан дип исәпләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
1нче кушымта
30 май 2014 ел № 10-14/кс

## Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызу хезмәтен күрсәткән оешмалары өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызу тарифлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешма, муниципаль берәмлек исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (берставкалы), сум/куб.м | Ташландык суны агызу тарифы (берставкалы), сум/куб.м | Ташландык суны агызу тарифы (өске катлам ташлындык сулар) (берставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | 1.07. 2014 алып 31.12.2014 кадәр | 1.07.2014 алып 31 .12.2014 кадәр | 1.07. 2014 алып 31.12.2014 кадәр |
| | Баулы муниципаль районы | | | |
| 1 | ЖЧЖ «Баулы-Водоканал»* | 28,24 | 17,71 | |
| | Алабуга муниципаль районы | | | |
| 2 | ААЖ «Алабуга» промышленность-җитештерү тибындагы махсус икътисади зонасы (тарифта ӨБС исәпкә алынмаган) | | | 25,74 |
| 3 | ААЖ «ПО Алабуга автомобилләр заводы» (тарифта ӨБС исәпкә алынмаган) | | | 15,42 |

<*> җиңеләйтелгән салым алу системасы кулланыла